| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.06.2025 г.Лениногорск № 34

2025 елда Лениногорск муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына кергән гражданнарның үзара салым акчаларын уртак финанслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү чараларын гамәлгә ашыруга гражданнарның үзара салымын җәлеп итүне стимуллаштыру максатларында, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Лениногорск муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына кергән гражданнарның үзара салым акчасының 1 сумына җирле бюджеттан 2 сумга тигез финанс ярдәме күрсәтергә.

2. «Финанс-бюджет палатасы» МКУ Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының авыл җирлекләре бюджетларына җирлекләр составына керә торган торак пунктлар өчен бюджетара трансфертлар бирергә.

3.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының җирле бюджетыннан 10 675 300 сум күләмендә акча бүлеп бирергә.

4. Финансланган акчаларны Лениногорск муниципаль районының авыл җирлекләре Уставында каралган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә.

5.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лениногорск муниципаль районы Советының бюджет, салымнар, финанс, икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә (Г.Р. Мәүлетова) йөкләргә.

Лениногорск муниципаль районы
Башлыгы урынбасары С.В.Тимаков